**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2767**
**21.04.2021**

Мәгариф хезмәткәрләре
арасында шәһәр һөнәри осталык
конкурслары үткәрү турында

Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5575 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, белем бирүнең сыйфатын күтәрү, педагогларның һөнәри педагогик иҗатын үстерү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә мәгариф хезмәткәрләре арасында һөнәри осталык конкурслары үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Яр Чаллы шәһәренең ел укытучысы» шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Елның өстәмә белем бирү педагогы» шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча;

3) «Шәхес тәрбияләргә» шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында нигезләмәне, 3 нче кушымтада каралганча;

4) «Ел педагог-психологы» шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында нигезләмәне, 4 нче кушымтада каралганча;

5) «Ел тәрбиячесе» шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында нигезләмәне, 5 нче кушымтада каралганча;

6) мәгариф хезмәткәрләре арасында шәһәр һөнәри осталык конкурсларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 6 нчы кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә мәгариф хезмәткәрләре арасында шәһәр һөнәри осталык конкурслары үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 1 084 521,44 (бер миллион сиксән дүрт мең биш йөз егерме бер) сум 44 тиен күләмендә, 7 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 21 апрелендәге
2767 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәренең ел укытучысы»
шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Яр Чаллы шәһәренең ел укытучысы» шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) шәһәр Хакиме инициативасы буенча Башкарма комитет тарафыннан ел саен үткәрелә, «Россия ел укытучысы» Бөтенроссия һөнәри конкурсының шәһәр этабы булып тора. Конкурсны оештыручылар булып Башкарма комитетның мәгариф идарәсе һәм «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе тора.

2. Конкурсның төп максаты булып түбәндәгеләр тора:

1) белем бирү сыйфатын күтәрү, укытучы һөнәренең абруен күтәрү, шәһәрнең талантлы педагогларын ачыклау, аларга ярдәм күрсәтү һәм бүләкләү;

2) иҗтимагый үсешнең өстенлекле юнәлешләрен билгели торган социаль институт буларак, мәгариф системасы турында иҗтимагый фикер формалаштыру;

3) муниципаль мәгариф системасы педагогия хезмәткәрләренең иҗади потенциалын ачу;

4) укытучыларга үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

3. Конкурсны үткәрү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) претендентның эш системасын һәм һөнәри-педагогик осталыгын, культура дәрәҗәсен, шулай ук белем бирүнең фәнни-методик проблемаларын һәм аларны чишү юлларын күрү сәләтләрен бәяләү;

2) белем бирү эчтәлегендә һәм технологияләрендә инновацияләрне, белем бирү процессын оештыруда яңа алымнарны һәм ысулларны анализлау;

3) конкурсантларның һөнәри-әһәмиятле, иҗади сыйфатларын ача торган чаралар.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

5. Конкурста башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы гомуми белем бирү ошмаларының педагоглары, «Ел укытучысы» мәктәп конкурсларында җиңүчеләр катнаша ала.

6. Конкурс үткәрү барышында оештыру комитеты тарафыннан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында иҗади эшләүче югары һөнәри дәрәҗәгә ия мәгариф хезмәткәрләре ачыклана.

7. Кандидатларны конкурсның шәһәр этабында катнашуга тәкъдим итү шәһәрнең муниципаль гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан башкарыла (конкурсларның мәктәп турларында җиңүчеләр).

8. Конкурсның мәктәп туры җиңүчесе нинди дә булса сәбәпләр буенча конкурсның шәһәр этабында катнаша алмаган очракта, муниципаль гомуми белем бирү оешмасы конкурска икенче урын алган катнашучыны җибәрергә хокуклы.

9. Конкурста катнашу ирекле.

10. Конкурсның беренче турында катнашучыларның составы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының үз-үзен тәкъдим итү тәртибендә катнашкан яки предметка бәйле методик берләшмәләрнең рекомендацияләре буенча җибәрелгән укытучылардан һәм педагоглардан формалаштырыла.

11. Конкурсның беренче туры шәһәр муниципаль гомуми белем бирү оешмалары базасында үткәрелә.

Һәрбер муниципаль гомуми белем бирү оешмасы конкурсның беренче турын үткәрү тәртибен билгели. Оештыру комитеты, муниципаль гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан тәкъдим ителгән конкурс сынаулары нәтиҗәләре нигезендә, предмет юнәлешләре буенча иң яхшы укытучыларны билгели.

12. Беренче тур түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

1) башлангыч сыйныфлар укытучысы;

2) татар теле һәм әдәбияты укытучысы;

3) гуманитар цикл укытучысы (рус теле һәм әдәбияты, чит телләр, тарих һәм җәмгыять белеме);

4) табигый-математик цикл укытучысы (математика һәм информатика, география, биология, физика, химия);

5) спорт-эстетик цикл укытучысы (физик культура, тормыш иминлеге нигезләре, музыка, рәсем, технология).

Беренче турның конкурс ярышлары нәтиҗәсендә икенче турга һәрбер муниципаль белем бирү оешмасыннан бер яки күбрәк кандидат – беренче тур җиңүчесе күрсәтелергә мөмкин.

13. Икенче һәм өченче турлар түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

1) башлангыч сыйныфлар укытучысы;

2) татар теле һәм әдәбияты укытучысы;

3) гуманитар цикл укытучысы (рус теле һәм әдәбияты, чит телләр, тарих һәм җәмгыять белеме);

4) табигый-математик цикл укытучысы (математика һәм информатика, география, биология, физика, химия);

5) спорт-эстетик цикл укытучысы (физик культура, тормыш иминлеге нигезләре, музыка, рәсем, технология);

6) укытучы-ветеран (педагогик эш стажы 20 елдан артык).

14. Конкурсның икенче (сайлап алу) турында катнашучыларның составы конкурсның беренче туры җиңүчеләреннән формалаштырыла.

15. Конкурсның икенче турында катнашучыларны теркәү өчен «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесенә (Чулман проспекты, 56, тел. 52-51-62) түбәндәге документлар тапшырыла:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмасыннан конкурста катнашуга заявка (кәгазьдә);

2) конкурсантның анкетасы (электрон төрдә).

16. Конкурсның икенче (сайлап алу) туры «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе базасында үткәрелә.

Икенче (сайлап алу) туры нон-стоп режимында бер көндә үткәрелгән түбәндәге сынаулардан тора:

1) конкурсантның үз-үзенә презентация (Мин, тәҗрибә, конкурста катнашуны нигезләү, мин …ошаган, чөнки…);

2) дәресне проектлаштыру;

3) мәгънәле укуны үстерү буенча тәҗрибә күрсәтү;

4) дәрес фрагментына анализ;

5) педагогик советта катнашу.

17. Икенче (сайлап алу) тур конкурсантларының эшчәнлек нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары (билге 2 баллга кадәр, барлык сынаулар өчен максималь сан –100 балл):

1) мәгълүмати һәм тел грамоталылыгы;
2) нәтиҗәлелек;
3) методик осталык һәм иҗат;
4) укуга мотив булдыру;
5) рефлексия һәм бәяләү;
6) оештыру культурасы;
7) нәтиҗәле коммуникация;
8) кыйммәтләр ориентирлары;
9) метапредметлылык һәм предметара интеграция;
10) мөстәкыйльлек һәм иҗат.

18. Оештыру комитеты икенче (сайлап алу) тур нәтиҗәләре буенча рейтинг буенча иң югары балл җыйган һәм конкурсның өченче (урында үткәрелә торган) турында катнашуны дәвам итәчәк укытучыларны билгели – 30 дан да ким түгел.

19. «Укытучы-профессионал – Практик» өченче (урында үткәрелә торган) тур түбәндәге конкурс сынауларын үз эченә ала:
1) дәрес;
2) дәрестән тыш чара.

20. «Дәрес» конкурсы сынавы.

Максат: конкурсант тарафыннан дәресне проектлаштыру, оештыру, үткәрү һәм аңа үзанализ ясау өлкәсендә укытучының һөнәри компетенцияләрен һәм иҗат потенциалын күрсәтү.

Конкурс сынавының форматы: конкурсның оештыру комитеты тарафыннан расланган, конкурсант тарафыннан гомуми белем бирү оешмасында үткәрелә торган дәреснең проекты, предмет буенча дәрес, үзанализ.

Дәреснең темасы конкурсның оештыру комитеты тарафаннан өченче (урында үткәрелә торган) турны үткәрү мәйданчыгы сыйфатында расланган гомуми белем бирү оешмасы укытучысының календарь-тематик планлаштыруы һәм тиешле предмет буенча тиешле классларда аның фактик үтәлүен исәпкә алган эшче программа нигезендә билгеләнә.

Конкурсант укыта торган предмет әлеге гомуми белем бирү оешмасында өйрәнелмәгән очракта, дәрес ирекле темага үткәрелә.

Конкурс сынавының регламенты: проектны тәкъдим итү 5 минутка кадәр, дәрес үткәрү – 45 минут, үзанализ һәм оештыру комитетының сорауларына җаваплар – 5 минутка кадәр.

21. «Дәрес» конкурсы сынавын бәяләү критерийлары (билгеләр 1 дән 10 баллга кадәр, максималь сан 100 балл):
1) дәрес проектын эшләү, нигезләү һәм тәкъдим итү;
2) предметның эчтәлеге;
3) оештыру культурасы;
4) методик/һөнәри бурычларны чишүгә иҗади якын килү;
5) психологик-педагогик һәм коммуникатив культура;
6) һөнәри эшчәнлекнең инновацияле өлеше;
7) мәгълүмати һәм тел грамоталылыгы;
8) һөнәри-шәхес сыйфатлары;
9) нәтиҗәлелек;
10) үткәрелгән дәреснең рефлексиясе.

22. «Дәрестән тыш чара» конкурсы сынавы.

Максат: конкурсантның предметара кыйммәтләргә ориентлашкан эчтәлектәге чаралар белән тәрбия бурычларын чишүгә юнәлдерелгән дәрестән тыш чараны оештыру, үткәрү һәм үзанализ өлкәсендәге һөнәри компетенцияләрен күрсәтү.

Конкурс сынавын үткәрү форматы: конкурсның оештыру комитеты тарафыннан үткәрү мәйданчыгы сыйфатында расланган, гомуми белем бирү оешмасында конкурсант

тарафыннан үткәрелә торган дәрестән тыш чара.

Регламент: дәрестән тыш чара үткәрү – 30 минут; дәрестән тыш чарага үзанализ һәм оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җаваплар – 15 минутка кадәр.

Дәрестән тыш чараның юнәлешен, темасын, формасын конкурсант мөстәкыйль сайлый.

Дәрестән тыш чара дәрестән тыш эшчәнлек характерына туры килә торган формада үткәрелә (сыйныф сәгате, мәктәп түгәрәкләрендәге, студияләрдәге, клублардагы һ.б. дәрес).

23. «Дәрестән тыш чара» конкурсы сынавын бәяләү критерийлары (билгеләр 1 дән 10 баллга кадәр, максималь сан 80 балл):

1) дәрестән тыш чараны оештыру һәм үткәрүнең тиешле максаты;

2) дәрестән тыш чарага сайланган теманың актуальлеге һәм нигезле булуы;

3) предметара кыйммәтләргә ориентлашкан эчтәлек;

4) тәрбия чараларын чишүгә иҗади һәм инновацияле якын килү;

5) психологик-педагогик һәм коммуникатив культура;

6) дәрестән тыш чараны оештыру һәм үткәрү;

7) мәгълүмати һәм тел грамоталылыгы;

8) үткәрелгән дәрестән тыш чараның рефлексиясе.

24. Өченче тур нәтиҗәләре буенча бәяләү критерийларында каралганча, иң күп балл җыйган, конкурсның финалына чыгучы 13 педагог билгеләнә.

25. Өченче турның финалга узмаган катнашучылары түбәндәге номинацияләр буенча дипломнар белән бүләкләнәләр: «Укытучы-профессионал», «Укытучы-профессионал – Аналитик», «Укытучы-профессионал – Практик», «Укытучы-профессионал – Педагог-Психолог», «Педагогик дебют», «Педагогикада традицияләр һәм новаторлык», «Укытучы-энтузиаст», «Фәнгә адым», «Иң креатив укытучы», «Илһам һәм педагогик артистлык».

26. Конкурста катнашучыларның үз тәҗрибәләрен трансляцияләү, предметара һәм гомуми педагогик проблемаларны формулировкалау, педагоглар арасында лидер булу сәләтләрен билгеләү финалның бурычы булып тора. Финал нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында «Россия ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының зональ этабында катнашучылар билгеләнә.

27. Конкурсның финалы түбәндәге конкурс сынауларын үз эченә ала:

1) мастер-класс;

2) педагогик проект;

3) педагогик совет;

4) ачык лекция.

28. Мастер-класс «Белем бирүнең сыйфатын күтәрү шарты буларак педагогның методик системасы» темасына үткәрелә.

Максат: конкурс финалистларының интерактив һөнәри аралашу шартларында шәхси инновацияле педагогик тәҗрибәсен тапшыру өлкәсендәге һөнәри осталыкларын күрсәтү.

Конкурс сынавының форматы: иң яхшы педагогик тәҗрибәне һәм инновацияле практикаларны трансляцияләү максатында белем бирү технологияләрен (методларын, нәтиҗәле ысулларын һ.б.) ачык рәвештә индивидуаль презентацияләү.

Регламент: мастер-класс үткәрү – 20 минут; оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җаваплар – 10 минутка кадәр.

«Мастер-класс» конкурс биремен бәяләү критерийлары (билгеләр 1 дән 10 баллга кадәр, максималь сан 100 балл):

1) актуальлек һәм методик нигезләнгән булу;

2) тәкъдим ителгән мастер-классның кыйммәтләр ориентирлары һәм белем бирү потенциалы;

3) метапредметлылык һәм предметара характер;

4) тәкъдим ителә торган тәҗрибәнең инновация өлеше;

5) практик әһәмияте һәм кулланылышы;

6) тәҗрибәне тәкъдим итүгә иҗади якын килү;

7) коммуникатив культура һәм аудитория белән һөнәри хезмәттәшлек;

8) мәгълүмати һәм тел грамоталылыгы;

9) рефлексив культура;

10) мастер-классның нәтиҗәлелеге.

29. «Белем бирү проекты» конкурс сынавы.

Максат: проектлаштыру культурасын, белем бирүнең социокультура проблематикасы чыганакларын һәм факторларын аңлауны, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның актуаль запросларын күрүне, командада нәтиҗәле эшли һәм конструктив хезмәттәшлек урнаштыра белүне, эшли торган проект модельләре булдыруны күрсәтү.

Конкурс сынавының форматы: конкурсантларның жирәбә салу нәтиҗәләре буенча формалаштырылган өч төркеме (проект төркемнәре) реаль вакыт режимында гомуми белем бирү оешмалары өчен актуаль проблемалы ситуацияне чишүгә юнәлдерелгән проект төзиләр.

Регламент: конкурсантларга белем бирү оешмалары өчен актуаль проблемалы ситуацияне тәкъдим итү – 30 минут; жирәбә салу нәтиҗәләре буенча проект төркемнәрен формалаштыру – 10 минут; проектны эшләү һәм тәкъдим итү өчен электрон һәм/яки башка форматта ясау – 4 сәгать; проектны сәхнәдә тәкъдим итү (яклау) – 15 минут; оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җаваплар – 10 минутка кадәр.

Һәрбер конкурсантның белем бирү проектын төркем белән эшләүдә һәм тәкъдим итүдә шәхси катнашуы бәяләнә.

30. Конкурс сынавын бәяләү критерийлары (билгеләр 1 дән 10 баллга кадәр, максималь сан 50 балл):

1) проектның проблемасын һәм максатын билгеләү;

2) тәкъдим ителә торган педагогик карарларның ышандырырлык булуы һәм аргументациясе;

3) куелган проект бурычын чишүгә инновацияле якын килү;

4) проектның тулылыгы, тормышка ашучанлыгы һәм реалистик булуы;

5) коммуникатив культура һәм һәрбер катнашучының проектны эшләүгә һәм презентацияләүгә керткән өлеше.

31. «Педагогик совет» конкурс сынавы.

Максат: булган проблемалар, аларны хәл итү юллары һәм мәгарифне үстерү перспективалары буенча фикер алышу өчен ачык һөнәри киңлек оештыру.

Конкурс биременең форматы: бирелгән темага индивидуаль чыгышлар һәм гомуми фикер алышу белән дискуссия. Регламент – 45 минутка кадәр. Дискуссиянең темасы алдагы көндә игълан ителә.

«Педагогик совет» конкурс биремен бәяләү критерийлары (билгеләр 1 дән 10 баллга кадәр, максималь сан 50 балл):

1) проблеманы аңлау;

2) позициянең ышандырырлык булуы һәм аргументациясе;

3) хезмәттәшлек һәм коммуникатив культура;

4) иҗади якын килү һәм фикерләрнең оригинальлеге;

5) мәгълүмати һәм тел культурасы.

## 3 бүлек. Йомгак ясау

32. Оештыру комитетының конкурс йомгаклары турында карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

33. Финал йомгаклары буенча иң күп балл җыйган конкурсант конкурста җиңүче

дип танылa. Финал йомгаклары буенча 2, 3 урыннарны алган катнашучылар конкурс призерлары дип санала. Финалда 4-11 урыннарны алган катнашучылар конкурсның лауреатлары дип санала.

34. Конкурста җиңүчеләр, призерлар һәм лауреатлар дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 21 апрелендәге
2767 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Елның өстәмә белем бирү педагогы»
шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Елның өстәмә белем бирү педагогы» шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) укучыларны иҗади һәм һөнәри үстерүдә, аларның гомуми культурасын формалаштыруда балаларга өстәмә белем бирүнең ролен күтәрүгә юнәлдерелгән.

2. Конкурс «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе белән берлектә Башкарма комитетның мәгариф идарәсе тарафыннан үткәрелә.

3. Конкурсның максаты булып түбәндәгеләр тора:

1) өстәмә белем бирү өлкәсе педагогия хезмәткәрләренең һөнәри үсешенә булышлык итү;

2) өстәмә белем бирү өлкәсендә талантлы педагогларны һәм инновацияле педагагогик тәҗрибәне ачыклау һәм аларга булышлык итү;

3) өстәмә белем бирүнең югары нәтиҗәләрен тәэмин итүче педагогик эшчәнлекнең иң яхшы үрнәкләрен педагоглар берләшмәсенә тәкъдим итү;

4) тәрбия һәм өстәмә белем бирүнең эчтәлеген һәм аны технологик тәэмин итүне яңарту;

5) өстәмә белем бирү өлкәсендәге педагогия хезмәткәрләренә үзләренең иҗади һәм һөнәри индивидуальлекләрен күрсәтү, шәхес потенциалларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

6) халыкның, кызыксынган оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чараларының, педагоглар һәм ата-аналар җәмәгатьчелегенең игътибарын өстәмә белем бирү проблемаларына җәлеп итү.

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

2 бүлек. Конкурста катнашучылар

5. Конкурста өстәмә белем бирү педагоглары, балалар сәнгать мәктәпләре укытучылары, шәһәрнең муниципаль оешмаларда балаларга өстәмә белем бирүне гамәлгә ашыручы тренер-укытучылар катнаша ала. Катнашучыларның яше чикләнмәгән.

6. Конкурс сынауларына түбәндәгеләр кертелми:
- узган елларда катнашучылар;
- узган елгы җиңүче оешма.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

7. Конкурс ике этапта үткәрелә:
1 этап – муниципаль оешмаларда;
2 этап – сайлап алу;
3 этап – финал.

8. Сайлап алу этабында катнашу өчен оештыру комитетына centrchelny@mail.ru электрон адресына һәр катнашучыга түбәндәге документларны җибәрергә кирәк:

1) заявка (электрон төрдә җибәрелә);

2) белем бирү программасының тексты бер нөсхәдә басма рәвештә;

3) катнашучының төсле фоторәсеме (электрон төрдә);

9. Конкурска җибәрелгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

10. Конкурсның җиңүчеләре барлык конкурс этапларының йомгаклары нигезендә рейтинг күрсәткечләре буенча билгеләнә.

## 4 бүлек. Сайлап алу этабын үткәрү

11. Сайлап алу этабына әзерләнгәндә, аның катнашучыларына түбәндәге биремнәрне үтәргә әзерләнергә кирәк:

1) «Өстәмә гомуми белем бирү программасын яклау. Тормышка ашырыла торган өстәмә гомуми белем бирү программасының конкурс программа-методик комплектын презентацияләү» конкурсы;

2) «Өстәмә гомуми белем бирү программасы нигезендә яңа эшчәнлек төре белән танышу» ачык дәресе;

3) «Күптөрле педагогик ярышлар» конкурсы.

12. «Өстәмә гомуми белем бирү программасын яклау. Тормышка ашырыла торган өстәмә гомуми белем бирү программасының конкурс программа-методик комплектын презентацияләү» конкурсы:

конкурс сынавының форматы – өстәмә гомуми белем бирү программасын яклау. Тормышка ашырыла торган программаның программа-методик комплектын презентацияләү түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала:

- программаның аннотациясе (4 биткә кадәр);

- программага төп методик эшләнмәләрнең аннотациясе (5 биткә кадәр);

- укытуның үзара чагыштырыла торган чорлары өчен программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелегенең таблицаларда яки графикларда (2 биткә кадәр) тәкъдим ителгән динамикасы, белем бирү оешмасының рәсми сайтында урнаштырылган күрсәтелгән программа-методик документларның тулы текстына сылтамалар белән.

Регламент – чыгыш ясауга 5 минутка кадәр һәм оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җаваплар өчен 5 минутка кадәр.

13. «Өстәмә гомуми белем бирү программасын яклау. Тормышка ашырыла торган өстәмә гомуми белем бирү программасының конкурс программа-методик комплектын презентацияләү» конкурсында чыгыш ясауны бәяләү (максималь балл – 55):

1) өстәмә гомуми белем бирү программасының эчтәлегенең һәм структурасының, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 9 пункты, Россия Мәгариф министрлыгының 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы Приказы нигезендә, өстәмә гомуми белем бирү программаларының эчтәлегенә һәм структурасына карата таләпләргә туры килүе;

2) педагогик максатларны һәм бурычларны билгели, сайлап алынган эшчәнлек төрен үзләштерүгә юнәлдерелгән дәресләр һәм (яки) дәресләр циклын планлаштыра белү;

3) актуальлек, яңалык һәм эшләнгән программаның норматив хокукый нигезе булу;

4) өстәмә гомуми белем бирү программасын тормышка ашыруның программа-методик тәэминатын эшли белү;

5) үз программаңның планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүен бәяләү системасын эшли белү;

6) укучыларның программаны үзләштерү процессына һәм нәтиҗәләренә үз контролен һәм үз бәяләвен формалаштыру һәм үстерү өчен педагогик шартлар тудыру;

7) педагогик контрольне һәм өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерүне бәяләүне гамәлгә ашыра белү;

8) программаны тормышка ашыру чорында уңай нәтиҗәлелек динамикасы;

9) оешма сайтына чыга торган актив сылтамалар булуны күрсәтү;

10) өстәмә гомуми белем бирү программасының һәм презентация материалларының бизәлеш сыйфаты;

11) конкурсантның үз-үзен тоту һәм сөйләм культурасы, тыңлаучыны кызыксындыру күнекмәләренә ия булу.

14. «Өстәмә гомуми белем бирү программасы нигезендә яңа эшчәнлек төре белән танышу» ачык дәресе:

1) укучылар белән дәрес дәвамлылыгы – 20 минут. Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен – 15 минут;

2) конкурсант дәресне үзенә таныш булмаган укучылар төркеме белән үткәрә. Педагогка катнашучылар сыйфатында җәлеп ителгән балалар төркемен программа эчтәлеге нигезендә теге яки бу яңа эшчәнлек төренә алып керергә кирәк;

3) конкурсант дәрескә үзанализ үткәрә һәм оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җавап бирә – 5 минутка кадәр.

15. Ачык дәресне бәяләү критерийлары (максималь балл – 55):

1) дәреснең педагогик максатларын һәм бурычларын билгели белү, укучыларның өстәмә гомуми үстерү программасын үзләштерүгә юнәлдерелгән яңа эшчәнлек төрен оештыра белү;

2) дәресләрдә укучыларның эшчәнлеген оештыруның педагогик нигезләнгән формаларын, методларын, чараларын һәм ысулларын файдалана белү;

3) дәрестә укучыларның эшчәнлеген һәм аралашуын стимуллаштыра һәм мотивацияли белү;

4) программаның үзенчәлекләрен һәм укучыларның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне, электрон белем бирү һәм мәгълүмат ресурсларын максатка яраклы һәм нигезле файдалана белү;

5) педагогик һәм агымдагы контрольне, белем бирү эшчәнлеген бәяләүне гамәлгә ашыра белү;

6) дәреснең һөнәри ориентация мөмкинлекләрен файдалана белү;

7) уңай психологик климат һәм укучыларга педагогик ярдәм формалаштыру өчен педагогик шартлар тудыра белү;

8) дәреснең төгәлләнгән булуын, аны үткәрү формасының оптимальлеген тәэмин итә белү;

9) укучыларның үзара хезмәттәшлеген оештыра белү;

10) үткәрелгән дәресне анализлау сыйфаты;

11) анализда мөстәкыйльлек дәрәҗәсе, һөнәри терминологияне белү.

16. Конкурс «Күптөрле педагогик ярышлар».

Конкурс сынавының форматы – биремнәрнең алмашынуы, эзлеклелеге һәм нон-стоп режимында үтәлүе:

1) «Бирелгән темага эссе»;

2) «Педагогик мәсьәлә. Педагогик ситуацияне анализлау һәм чишү. Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирүнең актуаль проблемалары буенча сорауларга җаваплар».

Конкурсантлар тарафыннан күптөрле педагогик ярышлар мәсьәләләренең үз чишелешләрен тәкъдим итү нон-стоп режимында ачык әңгәмәдә оештыру комитеты әгъзалары каршында гамәлгә ашырыла. Чишелешне индивидуаль тәкъдим итү вакыты 5 минуттан артык түгел.

17. «Бирелгән темага эссе» биреме.

Конкурс сынавы үткәрелә торган көнне катнашучыларга тәмамланган эчтәлеккә ия аерым бер фикер тәкъдим ителәчәк. Катнашучыга 40 минут эчендә эссе язарга кирәк.

Эссе ул – теманы иҗади аңлауны таләп итә торган инша-фикерләүнең бер төре, анда автор фикере, проблеманы үзеңнең ничек күрүең һәм үз тәҗрибәңә нигезләнеп аны чишү юллары мөһим. Эсседа проблеманы төгәл билгеләү, авторның фикерләре, уйлары хуплана. Текст мәгънәви яктан бөтен, бәйләнешле булырга, эзлеклелек үтәлергә тиеш. Конкурсантларга үзләренең уйларын һәм фикерләрен халык алдында демонстрацияләргә кирәк.

Чыгыш регламенты – 5 минутка кадәр.

18. Бәяләү критерийлары (максималь балл – 50):

1) жанрга туры килү;

2) теманың ачуның тулылыгы;

3) язуның ачык, төгәл һәм грамоталы булуы;

4) язуда логика һәм аргументлылык булу;

5) автор позициясе;

6 идеянең һәм фикерләрнең эчтәлегенең оригинальлеге;

7) өстәмә белем бирү өлкәсе һәм җәмгыять үсешенең заманча тенденцияләрен һәм стратегияләрен аңлау;

8) рефлексиягә сәләт булу һәм үзеңнең һөнәри эшчәнлегеңә педагогик күзәтү һәм анализ үткәрә белү;

9) тәкъдимнәрнең актуальлеге һәм максатка туры килүе, аларны тормышка ашыру мөмкинлекләрен исәпкә алып;

10) халык алдында чыгыш ясау культурасы.

19. «Педагогик технологияләр һәм һәрбер баланың уңышка ирешүен тәэмин итү практикасы» темасы буенча «Педагогик мәсьәлә» биреме.

Конкурс сынавы кысаларында өстәмә белем бирү педагогының эшчәнлегендә белем бирү, педагогик технологияләрне куллануга педагогик мәсьәлә конкрет текст контентларында, шул исәптән цифрлы төрләрне кулланып, формалаштырыла, аларны үтәү, чишү, тәкъдим итү халык алдында реаль вакыт режимында гамәлгә ашырыла. «Педагогик технологияләр һәм һәрбер баланың уңышка ирешүен тәэмин итү практикасы» темасы буенча күптөрле педагогик ярышларның педагогик мәсьәләсен чишү конкурсантның тәҗрибәсен һәм ул эшләгән оешманың үзенчәлекләрен анализлау нигезендә, конкурсант тарафыннан «Һәрбер баланың уңышы» федераль проектның төп бурычлары анализлануын һәм файдаланылуын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

20. Бәяләү критерийлары (максималь балл – 25):

1) норматив документларны белү;

2) һөнәри педагогик компетенцияләрне белү;

3) ситуацияләрнең һәм мәсьәләләрнең максатына туры килә торган методлар һәм технологияләр куллана белү;

4) тәкъдим ителә торган чишелешләрнең креативлыгы һәм оригинальлеге;

5) җаваплы карарлар кабул иткәндә мөстәкыйльлек күрсәтә белү.

21. «Педагог – ата-ана – укучы» темасы буенча «Педагогик ситуация» биреме. Педагогик ситуация – бала (балалар) һәм олы кеше (педагоглар һәм (яки) ата-аналар) хезмәттәшлегенең проблемалы ситуациясе, конкурсант аны караганнан, анализ ясаганнан соң әлеге ситуация буенча халык алдында үзенең педагогик чишелешен тәкъдим итә (күрсәтә), конкурсантның тәҗрибәсен һәм конкурсант эшли торган оешманың үзенчәлекләрен анализлау нигезендә, оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына халык алдында җавап бирә.

22. Бәяләү критерийлары (максималь балл – 25):

1) норматив документларны белү;

2) һөнәри педагогик компетенцияләрне белү;

3) ситуацияләрнең һәм мәсьәләләрнең максатына туры килә торган методлар һәм

технологияләр куллана белү;

4) тәкъдим ителә торган чишелешләрнең креативлыгы һәм оригинальлеге;

5) җаваплы карарлар кабул иткәндә мөстәкыйльлек күрсәтә белү.

## 5 бүлек. Финал

23. Сайлап алу этабы нәтиҗәләре буенча, бәяләү критерийларында каралганча иң күп балл җыйган, конкурсның финалына чыгучы 6 конкурсант билгеләнә.

24. Конкурсның финалына әзерләнгән вакытта анда катнашучыларга түбәндәге конкурс биремнәрен үтәргә әзерләнергә кирәк:

1) «Һөнәри берләшмәгә минем педагогик хат» презентациясе;

2) «4К: команда төзү, креативлык, коммуникацияләр, компетенцияләр» импровизацияләнгән конкурсы.

25. «Һөнәри берләшмәгә минем педагогик хат» конкурс – презентациясе. Һөнәри берләшмәгә педагогик хат – ачык һөнәри педагогик риториканың жанры һәм эчтәлеге, анда педагог һөнәри педагогик кыйммәтләрне, идеалларны, максатларны, бурычларны һәм конкрет шартларда һәм программаны тормышка ашыру үзенчәлекләрендә аларны үзенең педагогик эшчәнлегендә гәүдәләндерү ысулларын трансляцияли. Педагогик хатның эчтәлеге һәм формасы конкурсант тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә. Һөнәри хатның максатына ирешү өчен визуаль, музыкаль, күрсәтмә, презентацион, мәгълүмати – коммуникатив тәэсир итү чараларыннан файдаланылырга мөмкин.

Чыгышның регламенты – 7 минутка кадәр.

26. Бәяләү критерийлары (максималь балл – 20).

1) өстәмә белем бирү өлкәсе үсешенең төп тенденцияләрен һәм стратегияләрен аңлау;

2) рефлексиягә сәләт һәм үзеңнең һөнәри эшчәнлегеңә педагогик күзәтү һәм анализ ясый белү;

3) тәкъдимнәрнең тормышка ашырылу мөмкинлеген исәпкә алып, аларның актуальлеге һәм максатка туры килүе;

4) халык алдында чыгыш ясау культурасы.

27. «4К: команда төзү, креативлык, коммуникацияләр, компетенцияләр». импровизацияләнгән конкурс конкурста катнашучыларның эчтәлеге конкурс сынавы башланыр алдыннан гына билгеле була торган бирем нигезендә төркемдә, командада эшләвенә юнәлдерелгән. Конкурс сынавының эчтәлеге катнашучыларның команда төзүгә сәләтле булуын, әзерлеген, күнекмәләрен, креативлыгыгын, коммуникацияләрен, компетенцияләрен ачыклый торган күмәк эшчәнлек процессын оештыруны үз эченә ала.

Финалистлар төркеме конкурс сынавының эчтәлеге һәм регламенты белән таныша һәм биремне үтәргә керешә. Биремне төркем белән үтәү барышында конкурсантлар мөстәкыйль аралашалар, хезмәттәшлек итәләр, биремне үтәүне һәм аның барышын планлаштыруны, аның нәтиҗәләрен тәкъдим итүне билгелиләр. Биремне үтәү, аның процессы һәм нәтиҗәләре оештыру комитеты әгъзалары каршында гамәлгә ашырыла.

28. Бәяләү критерийлары (максималь балл – 35).

1) командада нәтиҗәле эшли һәм конструктив һөнәри хезммәттәшлек урнаштыра белү;

2) күмәк эшчәнлек процессын оештыру һәм төркемне күмәк эшчәнлеккә кертү күнекмәләренә ия булу;

3) коммуникация, аралашу (тыңлау, ышандыру) техникаларына һәм ысулларына ия булу;

4) тәнкыйди фикер йөртү һәм коллектив карарлар кабул итү күнекмәләренә ия булу;

5) тәкъдим ителә торган карарларның һәм коммуникатив тактикаларның креативлыгы һәм оригинальлеге;

6) билгесезлек шартларында җаваплы карарлар кабул итүдә мөстәкыйльлек һәм лидерлык сыйфатлары күрсәтә белү;

7) проектлаштыру компетентлыгы.

## 6 бүлек. Йомгак ясау

29. Конкурска йомгак оештыру комитеты тарафыннан финал этабында ясала. Оештыру комитеты карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

30. Иң күп балл җыйган һәм 1, 2, 3 урыннарны алган катнашучылар конкурс җиңүчеләре булалар. Җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнәләр. Финалда катнашучыларның калганнары конкурс лауреатлары булалар, дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 21 апрелендәге
2767 номерлы карарына
3 нче кушымта

«Шәхес тәрбияләргә»
шәһәр һөнәри osталык конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Шәхес тәрбияләргә» шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) шәһәр мәгариф системасында нәтиҗәле эшләүче тәрбия өлкәсе педагогларына ярдәм күрсәтүгә, тәрбия бирүнең иң яхшы перспектив методикаларын һәм технологияләрен ачыклауга юнәлдерелгән.

2. Әлеге нигезләмәдә «тәрбия» төшенчәсе шәхесне үстерүгә, социомәдәни, рухи-әхлакый кыйммәтләр һәм Россия җәмгыятендә кабул ителгән кеше, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә укучыларның үзбилгеләнүе һәм социальләшүе өчен шартлар тудыруга, укучыларда патриотизм, гражданлык хисе, Ватанны саклаучылар истәлегенә һәм Ватан Геройларының батырлыгына, закон һәм хокук тәртибенә, хезмәт кешесенә һәм өлкән буынга хөрмәт, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыруга юнәлдерелгән эшчәнлек буларак карала.

3. Конкурсның максаты булып тәрбия процессын оештыруның иң яхшы тәҗрибәләрен ачыклау һәм трансляцияләү һәм муниципаль белем бирү оешмаларында педагогик эшчәнлек алып баручы тәрбия өлкәсе педагогия хезмәткәрләре, белгечләре эшчәнлегенең һөнәри әһәмиятен һәм җәмәгатьчелек тарафыннан танылуын арттыру тора.

4. Конкурсның бурычлары:

1) белем бирү оешмаларында тәрбия процессын оештыруны гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенә, квалификация үсешенә ярдәм итү;

2) белем бирү оешмаларында тәрбия процессын оештыру өлкәсендә талантлы педагогларны һәм инновацион педагогик тәҗрибәне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү;

3) һөнәри берләшмәгә тәрбия процессын оештыруның югары нәтиҗәләрен һәм сыйфатын тәэмин итүче педагогик эшчәнлекнең иң яхшы үрнәкләрен тәкъдим итү;

4) тәрбия өлкәсе белгечләренең һөнәри индивидуальлеген иҗади яктан күрсәтү, аларның шәхси потенциалын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

5) тәрбия өлкәсе белгечләренең һөнәри берләшмәләрен үстерү;

6) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару, башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, коммерцияле булмаган оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чараларының, киң педагогик, ата-аналар җәмәгатьчелегенең һәм иҗтимагый оешмаларның игътибарын белем бирү оешмаларында балаларны тәрбияләү һәм социальләштерү мәсьәләләренә җәлеп итү.

2 бүлек. Конкурсның оештыручылары

5. Конкурс Башкарма комитетның мәгариф идарәсе тарафыннан «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе белән берлектә үткәрелә.

6. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитеты карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

## 3 бүлек. Конкурста катнашучылар

7. Конкурста муниципаль белем бирү оешмаларының белем бирү процессында югары профессиональ дәрәҗәдә тәрбия эшчәнлеген оештыруны һәм тормышка ашыруны гамәлгә ашыручы педагогия хезмәткәрләре (алга таба – конкурста катнашучылар) катнаша ала:

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчеләре;
- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагог-оештыручылары (укучылар үзидарәсен, балалар иҗтимагый берләшмәләрен һәм хәрәкәтләрен оештыручылар).

8. Конкурста катнашу гариза буенча һәм ирекле характерга ия.

9. Конкурста катнашучыларның яше чикләнмәгән.

10. Педагогик стажга һәм һөнәри эшчәнлек тәҗрибәсенә таләпләр чикләнмәгән.

## 4 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

11. Конкурс ике номинациядә үтә:

1) «КЛАСС коллектив тәрбияләү».

Номинация сыйныф җитәкчеләре – укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән үзара эшчәнлекнең тулылыгын тәэмин итүче, сыйныф коллективын балалар төркем берләшмәләренең төп ячейкасы буларак формалаштыруга ярдәм итүче, шулай ук ата-аналарда һәм законлы вәкилләрдә балаларны, шул исәптән сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балаларны, ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, авыр тормыш хәлендә калган балаларны һәм башкаларны тәрбияләүгә җаваплы мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итүче нәтиҗәле тәрбия программалары, проектлары, методикалары һәм технологияләрен тормышка ашыручы заманча белем бирү оешмаларының белем бирү процессында тәрбия эшчәнлегенең төп оештыручылары өчен;

2) «Балалар иҗтимагый оешмаларының, берләшмәләренең тәрбия траекторияләре».

Номинация балалар иҗтимагый оешмалары һәм берләшмәләренең оештыручылары һәм җитәкчеләре, белем бирү процессында тәрбия эшчәнлеген оештыруны һәм тормышка ашыруны гамәлгә ашыручы, төрле социаль институтлар эшчәнлеге кысаларында балаларны, шул исәптән сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балаларны, ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, авыр тормыш хәлендә калган балаларны гражданлык, патриотик, экологик һәм башка социаль юнәлешләрдәге балалар иҗтимагый хәрәкәтләре һәм оешмаларының иҗтимагый әһәмияткә ия эшчәнлегенә җәлеп итү юлы белән тәрбияләүдә нәтиҗәле тәрбия программаларын, проектларын, методикаларын һәм технологияләрен тормышка ашыра торган педагог-оештыручылар өчен.

12. Конкурс ике турда үткәрелә:

1 тур – читтән торып үткәрелә торган;

2 тур – урында үткәрелә торган.

## 5 бүлек. Конкурсның эчтәлеге

13. Читтән торып үткәрелә торган тур түбәндәге конкурс биремнәрен үз эченә ала:

1) «Шәхесне шәхес тәрбияли» видеороликы;

2) «Тәрбия практикаларының яңа формалары» тәрбия эшчәнлегенең яңа формалары тәҗрибәсенә тасвирлама.

14. «Шәхесне шәхес тәрбияли» видеороликы – конкурсантның ялгамыйча һәм монтажсыз бер кадр белән төшерелгән видеомөрәҗәгате. Регламент 2 минутка кадәр.

Педагогның белем бирү оешмасындагы эшчәнлегенең асылын, аның көчле якларын, казанышларын һәм уңышларын ача.

Видеороликны бәяләү критерийлары (һәрбер параметр өчен билге 0 дән 3 баллга кадәр, максималь – 18 балл):

1) сәләтләренә һәм характерына карамастан, укучыларның үсешенә ярдәм итә торган тәрбия максатлары кую;

2) тәрбия программаларын проектлаштыру һәм тормышка ашыру;

3) тәрбия эшенең заманча, шул исәптән интерактив формаларын һәм алымнарын гамәлгә ашыру;

4) укучыларда танып-белү активлыгын, мөстәкыйльлекне, инициативаны, иҗади сәләтләрне үстерү, гражданлык позициясе, хәзерге заман шартларында хезмәткә һәм тормышка сәләт формалаштыру, укучыларда сәламәт һәм имин яшәү рәвешен формалаштыру;

5) баланың төрле эшчәнлек төрләренең (уку, уен, хезмәт, спорт, сәнгать һ. б.) тәрбия мөмкинлекләрен тормышка ашыру;

6) укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) конструктив тәрбияви тырышлыкларын файдалану, гаиләгә бала тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм итү.

15. «Тәрбия практикаларының яңа формалары» тәрбия эшчәнлегенең яңа формалары тәҗрибәсенең тасвирламасы оештыру комитетына centrchelny@mail.ru. электрон адреска җибәрелә. Тәҗрибә тасвирламасының күләме буш урыннарны да кертеп 7 000 билгегә кадәр, .doc форматында, шрифт үлчәме 14, TimesNewRoman шрифтында, интервал – 1,5. Эчтәлек темага туры килергә, укучыларны тәрбияләүдә яңа тәҗрибә һәм тәрбия практикаларының яңа формаларының әһәмиятлелеген тасвирларга, тәрбия өлкәсендәге хәзерге вәзгыятьне белүне, хәзерге заман куйган шартларда тәрбия эшенең төп кыйммәтләрен һәм юнәлешләрен аңлауны күрсәтергә тиеш.

16. Тәрбия проектын бәяләү критерийлары (һәрбер параметр өчен билге 0 дән 3 баллга кадәр, максималь – 12 балл):

1) актуальлек һәм теманың эчтәлегенә туры килү;

2) тәҗрибәнең инновацион булуы;

3) сайланган форманың куелган тәрбия максатларына, бурычларына туры килүе;

4) сайланган форманың нигезлелеге һәм бала тәрбияләүдә әһәмияте.

17. Урында үткәрелә торган тур «Тәрбияви вакыйга» ачык тәрбия чарасы конкурс сынавын үз эченә ала. «Тәрбияви вакыйга» ачык тәрбия чарасы катнашучылар өчен таныш булмаган бер төркем укучылар белән тәрбия чарасын оештыру рәвешендә, конкурс сынавы регламенты, халык алдында күрсәтү, ачык катнашу, сайлап алынган методик чаралар, технологияләр, ысуллар, практикалар, техника һ.б. демонстрацияләү шартларында уза. Чараның эчтәлеге, методлары һәм формасы конкурсант тарафыннан мөстәкыйль рәвештә әлеге тема кысаларында билгеләнә. Дәрес максатларына ирешү өчен кирәк булган һәм максатка ярашлы визуаль, музыкаль, күрсәтмә, презентацион, мәгълүмати-коммуникатив чараларны файдалану рөхсәт ителә. Ярдәмчеләрнең катнашуы рөхсәт ителми.

Укучылар белән үткәрелә торган чараның дәвамлылыгы: кече, урта һәм югары сыйныф укучылары белән – 30 минут.

Конкурсант оештыру комитеты әгъзалары алдында үткәрелгән чарага рефлексив үзанализ ясый (5 минутка кадәр).

Конкурс сынавының гомуми дәвамлылыгы – 35 минут.

18. Конкурс сынавы түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «КЛАСС коллектив тәрбияләү» номинациясендә катнашучылар өчен «Сыйныф сәгате»;

2) «Балалар иҗтимагый оешмаларының, берләшмәләренең тәрбия траекторияләре» номинациясендә катнашучылар өчен «Социаль юнәлешле проект».

19. «Тәрбияви вакыйга» ачык тәрбия чарасын бәяләү критерийлары (һәрбер параметр өчен билге 0 дән 3 баллга кадәр, максималь – 10 балл):

1) сәләтләренә һәм характерына карамастан, укучыларның үсешенә ярдәм итә торган тәрбия максатлары кую;

2) тәрбия эшенең заманча, шул исәптән интерактив формаларын һәм алымнарын гамәлгә ашыру;

3) укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) тәрбия бирүдә конструктив тырышлыкларын файдалану, гаиләгә бала тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм итү;

4) баланың эмоциональ-кыйммәтләр өлкәсен үстерә торган ситуацияләр һәм вакыйгаларны проектлаштыру;

5) укучыларда танып-белү активлыгын, мөстәкыйльлекне, инициативаны, иҗади сәләтләрне үстерү, гражданлык позициясе, хәзерге заман шартларында хезмәткә һәм тормышка сәләт формалаштыру;

6) уңай психологик климат формалаштыру һәм балаларга педагогик ярдәм күрсәтү өчен педагогик шартлар тудыра белү;

7) балаларның эшчәнлеген һәм аралашуын стимуллаштыра һәм мотивацияли белү;

8) эчтәлек, алымнар һәм чараларның куелган максатларга һәм бурычларга туры килүен билгеләү өчен чарага анализ ясый белү.

## 6 бүлек. Йомгак ясау

20. Йомгак оештыру комитеты тарафыннан, читтән торып үткәрелгән тур нәтиҗәләрен исәпкә алып, конкурс финалында ясала. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

21. «КЛАСС коллектив тәрбияләү» һәм «Балалар иҗтимагый оешмаларының, берләшмәләренең тәрбия траекторияләре» номинацияләренең һәрберсе буенча иң күп балл җыйган һәм 1, 2, 3 урыннарны алган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре булып санала. Җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнәләр.

22. «КЛАСС коллектив тәрбияләү» һәм «Балалар иҗтимагый оешмаларының, берләшмәләренең тәрбия траекторияләре» номинацияләренең һәрберсе буенча конкурста 1 урын алган җиңүче балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсе хезмәткәрләренең «Шәхес тәрбияләргә» республика һөнәри осталык конкурсының зональ һәм республика этапларына җибәрелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 21 апрелендәге
2767 номерлы карарына
4 нче кушымта

«Ел педагог-психологы»
шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Ел педагог-психологы» шәһәр һөнәри осталык конкурсының (алга таба – конкурс) максатларын һәм бурычларын, аны оештыру, үткәрү, йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү тәртибен билгели.

2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2. Конкурс Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары педагог-психологларының һөнәри дәрәҗәсен күтәрү һәм иҗади потенциалын тулаем тормышка ашыру, мәгариф системасында практик психология хезмәтенең абруен күтәрү максатында үткәрелә.

3. Конкурсның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) белгечләргә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру, аларның иҗади потенциалын ачу өчен шартлар тудыру;

2) шәһәр белем бирү системасының талантлы педагог-психологларын ачыклау, аларга ярдәм күрсәтү һәм бүләкләү;

3) барлык белем бирү дәрәҗәсендәге барлык тип һәм төр белем бирү оешмалары педагог-психологларының алдынгы эш тәҗрибәсен тарату.

3 бүлек. Конкурсның оештыручылары һәм катнашучылары

4. Конкурсның оештыручылары булып Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе, «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе тора.

5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

6. Конкурста муниципаль белем бирү оешмаларының педагог-психологлары катнаша. Катнашучыларның яше чикләнми, эш стажы 5 елдан ким түгел.

7. Конкурста катнашучыларны теркәү өчен «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесенә (алга таба – «ММҮ» МБУ) (Чулман проспекты, 56, тел. 52-51-63) муниципаль белем бирү оешмасыннан конкурста катнашуга заявка тапшырыла (кәгазьдә).

4 бүлек. Конкурсның эчтәлеге

8. Конкурс ике этапта үткәрелә:

1 этап – читтән торып үткәрелә торган;

2 этап – урында үткәрелә торган: ярымфинал һәм финал.

9. Читтән торып үткәрелә торган этап үз эченә ике конкурс сынавын ала: «Һөнәри эшчәнлек характеристикасы», «Визит карточкасы». Читтән торып үткәрелә торган этапның

барлык материаллары «ММҮ» МБУга тапшырыла.

10. «Катнашучының һөнәри эшчәнлек характеристикасы» читтән торып үткәрелә торган этапның беренче конкурс сынавы.

Формат: төп бүлекләр сыйфатында түбәндәгеләрне үз эченә алучы документ:

1) һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем турында мәгълүматлар;

2) конкурсант тарафыннан эшләнгән локаль яки методик документлар, медиапродуктлар, программалар, проектлар һәм башкалар исемлеге;

3) конкурсантның соңгы 3 ел өчен һөнәри эшчәнлегенең гомумиләштерелгән йомгаклары;

4) конкурсант тарафыннан кулланыла торган психологик-педагогик технологияләр, методикалар, программалар исемлеге.

11. «Катнашучының һөнәри эшчәнлек характеристикасы»н бәяләү критерийлары (максималь баллар саны – 20 балл):

1) эчтәлекле булу;

2) актуальлек;

3) мәгълүмат булу, конкурсантның эш тәҗрибәсен чагылдыру һәм материалларның практик әһәмияте;

4) «Педагог-психолог (белем бирү өлкәсе психологы)» һөнәри стандарт таләпләренең исәпкә алынуы;

5) мәгълүматны тәкъдим итү культурасы.

12. Читтән торып үткәрелә торган этапның «Визит карточкасы» икенче конкурс сынавы: педагог-психологны тәкъдим итүче, конкурсантның һөнәри эшчәнлеге кысаларында «Педагог-психолог (белем бирү өлкәсе психологы)» һөнәри стандарт таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган психологик-педагогик практиканы һәм/яки белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча инновацияле технологияне тормышка ашыру тәҗрибәсе турында сөйләүче видеоролик.

Формат: күпсанлы заманча цифрлы җайланмаларда: AVI, MPEG, MKV, WMV, FLV, FullHD һәм башкаларда күрсәтү мөмкинлеге булган, дәвамлылыгы 3 минуттан артмаган видеоролик; сыйфаты 360 px ким түгел; видеороликта катнашучының һәм ул тәкъдим итә торган оешманың исеме күрсәтелгән мәгълүмат язуы булырга тиеш. Видеороликның жанрын катнашучылар үзләре билгели (интервью, репортаж, видеоклип, мультфильм һ.б.).

13. «Визит карточкасы»н бәяләү критерийлары (максималь баллар саны – 20 балл):

1) темага туры килү (0 – 5 балл);

2) мәгълүмат булу (0 – 5 балл);

3) оригинальлек (0 – 5 балл);

4) мәгълүматның тулылыгы һәм аны бирүнең корректлылыгы (0 – 5 балл).

14. Конкурсның читтән торып уза торган этабы йомгаклары буенча гомуми рейтингта иң күп балл җыйган унике катнашучы (мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының алты педагог-психологы һәм гомуми белем бирү оешмаларының алты педагог-психологы), конкурсның урында үтә торган этабында (ярымфиналда һәм финалда) катнашалар.

15. Конкурсның ярымфиналы кысаларында конкурсантларның чыгыш ясау чираты конкурсны оештыручылар тарафыннан үткәрелә торган ачык жирәбә салу белән гамәлгә ашырыла.

16. Конкурсның ярымфиналы ике сынаудан тора: «Һөнәри квест» һәм «Мастер-класс».

17. «Һөнәри квест» конкурс сынавы.

Формат: катнашучы психодиагностик тикшерү беркетмәсенең мәгълүматларын анализлау нигезендә «Психологик бәяләмә» документы әзерләргә тиеш. Балаларның яше һәм конкурс сынавы биремнәре өчен проблематика оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә.

Регламент: 120 минуттан артык түгел.

18. «Һөнәри квест» сынавын бәяләү критерийлары (максималь баллар саны – 50 балл):

1) темага туры килү;

2) проблеманы ачу тирәнлеге һәм фикерләрнең ышандырырлык булуы;

3) үз фикереңне аргументлаштыру;

4) документ структурасына карата таләпләргә туры килү;

5) язуның логикалы, грамоталы булуы.

19. «Мастер-класс» конкурс сынавы.

Формат: хезмәттәшләре һәм оештыру комитеты алдында чыгыш ясау, монда конкурсантлар һөнәри эшчәнлек кысаларында гамәлгә ашырыла торган психологик-педагогик практиканы һәм/яки белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча инновацион технологияне тормышка ашыру тәҗрибәсен күрсәтәләр. «Мастер-класс» темасын катнашучы мөстәкыйль билгели. Регламент: катнашучының чыгышына 15 минут, оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына 5 минут.

20. «Мастер-класс» сынавын бәяләү критерийлары (максималь баллар саны – 70 балл):

1) гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары һәм «Педагог-психолог (мәгариф өлкәсе психологы)» һөнәри стандарты таләпләренә туры килүе;

2) нәтиҗәлелек (үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәләрен анализлый белү, төгәл алгоритм булу (фазалар, этаплар, процедуралар), актуальләштерүнең, проблемалаштыруның оригиналь алымнары, эзләү һәм ачу ысуллары, рефлексия, башка педагог-психологлар тарафыннан куллану мөмкинлеге булу);

3) нигезләнгән булу (эчтәлекнең актуальлеге һәм фәннилеге, гомумиләштерү сәләте);

4) эчтәлегенең тирәнлеге һәм оригинальлеге;

5) психологик-педагогик эшчәнлек өчен практик кыйммәте;

6) үз эш тәҗрибәңне трансляцияли (тапшыра) белү;

7) гомуми культура һәм коммуникатив сыйфатлар (эрудиция, стандарт булмаган фикер йөртү, аралашу стиле, импровизация сәләте).

21. Конкурсның ярымфиналы төгәлләнгәннән соң, оештыру комитеты тарафыннан конкурсантларның «Һөнәри квест» һәм «Мастер-класс» конкурс сынаулары өчен җыелган балларының гомуми санын исәпкә алып, ранжир ясау үткәрелә, конкурс финалында катнашу өчен алты конкурсант билгеләнә. Финалда җыелган баллар нульгә әйләндерелә.

22. Конкурс финалының эчтәлеге конкурсның бер «Һөнәри кейслар» сынавын үз эчен ала.

Формат: катнашучы психологик-педагогик проблеманы иллюстрацияли торган һәм проблемалы психологик-педагогик ситуацияне анализлау һәм бәяләүне, шулай ук проблеманы хәл итүне һәм карар кабул итүне демонстрацияли торган һөнәри кейс чишәргә тиеш.

Регламент: проблемалы ситуацияне чишүгә 7 минут, чыгыш ясауга 5 минут, оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына 3 минут.

23. «Һөнәри кейслар» конкурс сынавын бәяләү критерийлары (максималь баллар саны – 50 балл):

1) темага туры килү;

2) нәтиҗәлелек һәм аргументлылык;

3) эчтәлекле һәм нигезләнгән булу;

4) һөнәри эшчәнлекнең этика нормаларын үтәү;

5) сөйләмнең ышындырырлык һәм матур булуы.

## 5 бүлек. Конкурска йомгак ясау

25. Конкурска йомгак оештыру комитеты тарафыннан ясала һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

26. Конкурсның җиңүчесе итеп финал йомгаклары буенча иң күп балл җыйган конкурсант танылa. Финал йомгаклары буенча 2, 3 урыннарны алган катнашучылар конкурсның призерлары булып санала.

Финалда 4-6 урыннарны алган катнашучылар һәм финалга чыкмаган ярымфиналда катнашучылар конкурсның лауреатлары булып санала.

27. Конкурста җиңүче, призерлар – дипломнар һәм акчалата премияләр, лауреатлар дипломнар белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 21 апрелендәге
2767 номерлы карарына
5 нче кушымта

«Ел тәрбиячесе»
шәһәр һөнәри осталык конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Ел тәрбиячесе» шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) мәктәпкәчә белем бирү оешмалары педагоглары һөнәренең социаль дәрәҗәсен күтәрү, шәһәр педагоглары һөнәри эшчәнлегенең иң яхшы үрнәкләрен демонстрацияләү, җәмгыятьтә белем бирү өстенлекләрен раслау, иң яхшы педагогик тәҗрибәне ачыклау һәм тарату максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) мәктәпкәчә белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандартын кертү шартларында, педагогларны интеллектуаль һәм иҗади эшчәнлекнең яңа формаларын эзләүгә мотивацияләү һәм стимуллаштыру;

2) педагогларның һөнәри һәм карьера үсеше өчен шартлар тудыру, социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү;

3) шәһәр педагогларының һөнәри-педагогик осталыгын камилләштерү;

4) мәктәпкәчә белем бирү системасының талантлы педагогия хезмәткәрләрен ачыклау, аларга ярдәм итү һәм бүләкләү;

5) профессиональ аралашу диапазонын киңәйтү.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурста шәһәр мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының квалификацион категориясе булган тәрбиячеләре, балаларны татар теленә өйрәтүче тәрбиячеләр, педагог-психологлар, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар, музыка җитәкчеләре, физик культура буенча инструкторлар катнаша ала.

4. Документларны тапшыру вакытына кандидатларның педагогик эш стажы өч елдан ким булмаска тиеш.

5. Конкурста катнашу ирекле.

6. Кандидатлар түбәндәгеләр тарафыннан тәкъдим ителергә мөмкин:

1) мәктәпкәчә белем бирү оешмасының педагогия советы (коллективы) карары;

2) мәктәпкәчә белем бирү оешмасының ата-аналары (ата-аналар комитеты, попечительләр советы);

3) хезмәттәшләрнең инициатив төркеме;

4) үз-үзен күрсәтү юлы белән.

7. Конкурсның йомгаклау этабында җиңүчеләр һәм катнашучылар алдагы биш ел дәвамында конкурста катнашмыйлар.

3 бүлек. Конкурсның эчтәлеге

8. Конкурсны үткәрү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) претендентның эш системасын һәм һөнәри-педагогик осталыгын, культура дәрәҗәсен, шулай ук мәктәпкәчә белем бирүнең фәнни-методик мәсьәләләрен һәм аларны

хәл итү юлларын күрә белү сәләтен бәяләү;

2) мәктәпкәчә белем бирү эчтәлегендә һәм технологияләрендә инновацияләрне, тәрбия-белем бирү процессын оештыруның яңа алымнарын һәм ысулларын анализлау;

3) конкурсантларның һөнәри әһәмияткә ия, иҗади сыйфатларын ача торган чаралар.

9. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

10. Конкурсны үткәрү барышында оештыру комитеты тарафыннан иҗади алымнар куллана торган, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, ата-аналар һәм җәмәгатьчелек арасында югары һөнәри рейтингка ия хезмәткәрләр ачыклана.

11. Оештыру комитеты конкурс үткәрүнең һәр этабында конкурс үткәрүгә йомгак ясый, шулай ук конкурсның җиңүчеләрен раслый.

## 4 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

12. Конкурс өч этапта үткәрелә.

13. Беренче этапта педагоглар авторлык программасының иҗади презентациясен тәкъдим итәләр. Конкурсның оештыру комитетына (Башкарма комитет мәгариф идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге, 20/07А йорты, 2 кабинет, тел. 56-14-74) конкурста катнашу өчен заявкалар бирелә.

14. Оештыру комитеты презентацияләр үткәрү графигын төзи.

15. «Иҗади презентация» форматы үзеңнең һөнәри тәҗрибәңне, авторлык программасын, эшчәнлек планнарын һәм перспективасын иҗади формада күрсәтүдән гыйбарәт. Регламент – конкурста катнашучының чыгышына 7 минутка кадәр, оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына җавап бирүгә – 5 минутка кадәр.

16. «Иҗади презентация»не бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) авторлык программасы эчтәлегенең актуальлеге, белем бирү системасы өчен практик әһәмияте (0-5 балл);

2) авторлык программасының максатлары һәм бурычлары мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь һәм психологик үзенчәлекләренә, мәктәпкәчә белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандартына туры килүе (0-5 балл);

3) авторлык программасының (методик теманың) төп юнәлешләрен ачу (0-5 балл);

4) алымның яңалыгы һәм үзенчәлеге (0-5 балл);

5) педагог эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге (шәхси һөнәри тәҗрибәсе, тәрбияләнүчеләрнең мөһим казанышлары) (0-5);

6) коммуникатив культура (0-5);

7) киләчәккә планнар һәм перспективалар (0-1 балл).

17. Конкурсның икенче этабында беренче этапта иң күп балл җыйган 24 кеше катнаша.

18. Икенче этапта таныш булмаган балалар төркеме белән ачык рәвештә оештырылган белем бирү эшчәнлеген карау оештырыла. Темаларны һәм балаларның яшен жирәбә салу юлы белән оештыру комитеты әгъзалары билгели. Ачык рәвештә оештырылган белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча конкурста катнашучы үз-үзенә анализ ясый.

19. Ачык рәвештә оештырылган белем бирү эшчәнлеген бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) эчтәлекнең мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү өлкәләренә туры килүен тәэмин итә (0-2 балл);

2) эчтәлекнең тәрбияләнүчеләрнең яшь үзенчәлекләренә туры килүен тәэмин итә (0-2 балл);

3) эчтәлекнең тәрбия мөмкинлекләрен тормышка ашыра (0-2 балл);

4) тәрбияләнүчеләрнең сөйләм/ социаль-коммуникатив/ физик/ сәнгать-эстетик үсеше өчен шартлар тудыра (0-2 балл);

5) заманча фәнни белемнәргә туры килә торган, дөньяның хәзерге картинасын формалаштыруга ярдәм итә торган эчтәлекне тормышка ашыра (0-2 балл);

6) Россия җәмгыятенең традицион кыйммәтләренә туры килә торган эчтәлекне тормышка ашыра (0-2 балл);

7) тәрбияләнүчеләрнең игътибарын җәлеп итү һәм тоту алымнарын куллана (0-2 балл);

8) укучыларның инициативасына һәм мөстәкыйльлегенә ярдәм итү ысулларын файдалана (0-2 балл);

9) тәрбияләнүчеләрне стимуллаштыру һәм бүләкләү ысулларын куллана (0-2 балл);

10) күрсәтмә чараларны һәм мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне максатчан куллана (0-2 балл);

11) чара нәтиҗәләре буенча укучыларга рефлексия өчен шартлар тудыра (0-2 балл);

12) «Иҗади презентация» конкурс сынавы белән үзара бәйләнешне тәэмин итә;

13) чараның төгәл структурасын тәэмин итә (0-2 балл);

14) чараның максатлары һәм бурычлары нигезендә киңлекне зоналаштыра һәм аны нәтиҗәле куллана (0-2 балл);

15) санитария-гигиена нормаларын үти (0-2 балл);

16) чараның хронометражын үти (0-2 балл);

17) конкурс чарасы регламентын үти (0-2 балл);

18) тәрбияләнүчеләр белән эмоциональ элемтә урнаштыра (0-2 балл);

19) тәрбияләнүчеләр белән эшләүдә уңай психологик климат булдыра (0-2 балл);

20) чарада катнашучы барлык тәрбияләнүчеләрне игътибар үзәгендә тота (0-2 балл);

21) сөйләм хаталары ясамый (0-2 балл);

22) аралашу этикасы кагыйдәләрен үти (0-2 балл);

23) тәрбияләнүчеләр өчен төгәл, аңлаешлы, һәркем аңларлык итеп сораулар һәм биремнәр формалаштыра (0-2 балл);

24) эмоциональ тотрыклылыкны күрсәтә (0-2 балл);

25) индивидуаль һөнәри эшчәнлек стиле күрсәтә (0-2 балл).

20. Ачык рәвештә оештырылган белем бирү эшчәнлеген күрсәтү нәтиҗәләре буенча икенче этапта иң күп балл җыйган 9 катнашучы билгеләнә. Алар конкурсның финалистлары була.

21. Конкурсның өченче этап (финал) программасы «Мастер-класс» һәм түгәрәк өстәлдән тора.

22. «Мастер-класс» халык алдында мәктәпкәчә белем бирүне үстерүнең заманча технологияләрен чагылдыручы конкрет методик алымны, методны, тәрбияләү, белем бирү, үстерү һәм сәламәтләндерү технологиясен демонстрацияли торган чыгыш ясаудан гыйбарәт. Тема конкурсант тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә (регламент – 20 минутка кадәр).

25. «Мастер-класс»ны бәяләү критерийлары:

1) мәктәпкәчә белем бирү максатларына ирешү өчен күрсәтелә торган тәҗрибәнең әһәмиятен нигезли (0-2 балл);

2) күрсәтелә торган технологиянең/метод/ысулларның үз һөнәри эшчәнлегендә ролен һәм урынын билгели (0-2 балл);

3) күрсәтелә торган тәҗрибәнең педагогик нәтиҗәлелеген нигезли (0-2 балл);

4) күрсәтелә торган тәҗрибәнең мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты белән бәйләнешен билгели (0-2 балл);

5) тәкъдим ителә торан тәҗрибәнең кыйммәт, үстерү һәм тәрбияви тәэсирләренә игътибарны юнәлтә (0-2 балл);

6) тәҗрибәне мәктәпкәчә белем бирү практикасында тиражлау мөмкинлеген күрсәтә (0-2 балл);

7) тәкъдим ителә торган тәҗрибәне тормышка ашыру үзенчәлекләрен күрсәтә (0-2 балл);

8) күрсәтелә торган технологияне/методларны/алымнарны файдалану буенча конкрет рекомендацияләр тәкъдим итә (0-2 балл);

9) профессиональ аудиторияне активлаштыру методлары/алымнарының киң җыелмасын күрсәтә (0-2 балл);

10) мастер-класста катнашучылар белән конструктив хезмәттәшлек итә (0-2 балл);

11) мәгълүматны оптималь күләмдә һәм эчтәлек белән файдалана (0-2 балл);

12) файдалана торган мәгълүмат чыганакларын, аларның авторлыгын күрсәтә (0-2 балл);

13) мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне һәм күрсәтмә чараларны оптималь файдалана (0-2 балл);

14) оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына конкрет, төгәл һәм ачык итеп җавап бирә (0-2 балл).

24. Түгәрәк өстәл – мәктәпкәчә белем бирүнең актуаль мәсьәләләре буенча конкурсантларның мәктәпкәчә белем бирү үсешенең заманча тенденцияләрен белүен һәм аңлавын күрсәтергә мөмкинлек бирә торган ачыктан-ачык фикер алышу, дискуссия алып бара һәм үз фикереңне яклап кала белү, фикер алышудагы активлык. Регламент 60 минут. Әлеге сынау барышында конкурсантларга бәя бирелми.

## 5 бүлек. Конкурска йомгак ясау

25. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

26. Финалда 4-9 урыннарны алган катнашучылар конкурс лауреатлары булып санала. 2, 3 урыннарны алган конкурс катнашучылары конкурс призерлары булып санала. Конкурсның бәяләү критерийлары нигезендә, иң күп балл җыйган конкурс җиңүчесенә «Ел тәрбиячесе» исеме бирелә.

27. Конкурсның җиңүчесе, призерлары, лауреатлары дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева